КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 30 июль г.Казань № 635

2019 – 2024 елларга Татарстан Республикасында үзәкләштерелгән су чыгару системаларының чистарту корылмаларын төзү һәм реконструкцияләү (модернизацияләү) буенча төбәк программасын раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән 2019 – 2024 елларга Татарстан Республикасында үзәкләштерелгән су чыгару системаларының чистарту корылмаларын төзү һәм реконструкцияләү (модернизацияләү) буенча төбәк программасын расларга.

2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгына һәм Татарстан Республикасының Экология һәм табигый байлыклар министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы Р.К.Нигъмәтуллин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2019 ел, 30 июль, 635 нче
карары белән расланды

# 2019 – 2024 елларга Татарстан Республикасында үзәкләштерелгән су чыгару системаларының чистарту корылмаларын төзү һәм реконструкцияләү (модернизацияләү) буенча төбәк программасы

## I. Гомуми нигезләмәләр

Бу 2019 – 2024 елларга Татарстан Республикасында үзәкләштерелгән су чыгару системаларының чистарту корылмаларын төзү һәм реконструкцияләү (модернизацияләү) буенча төбәк программасы (алга таба – Төбәк программасы) 2024 ел ахырына Идел елгасына агызып төшерелә торган пычрак суларның өлешен өч тапкырга киметү максатларында «Экология» илкүләм проекты буенча проект комитеты утырышының 2018 елның 21 декабрендәге 3 номерлы беркетмәсе белән расланган «Иделне савыктыру» федераль проектын тормышка ашыру чаралары планы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе гражданнарын һәркем алырлык һәм уңайлы торак һәм коммуналь хезмәтләр белән тәэмин итү» Россия Федерациясе дәүләт программасын раслау турында» 2017 елның 30 декабрендәге 1710 номерлы карары белән расланган «Россия Федерациясе гражданнарын һәркем алырлык һәм уңайлы торак һәм коммуналь хезмәтләр белән тәэмин итү» Россия Федерациясе дәүләт программасы (алга таба – федераль дәүләт программасы) кысаларында «Россия гражданнарын сыйфатлы торак-коммуналь хуҗалык хезмәтләре белән тәэмин итү өчен шартлар тудыру» ярдәмче программасы нигезендә эшләнде.

## II. Төбәк программасы паспорты

| | |
|---|---|
| Программаның исеме | 2019 – 2024 елларга Татарстан Республикасында үзәкләштерелгән су чыгару системаларының чистарту корылмаларын төзү һәм реконструкцияләү (модернизацияләү) буенча төбәк программасы |
| Дәүләт заказчысы – Төбәк программасының координаторы | Татарстан Республикасының Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы |
| Төбәк программасының дәүләт заказчысы | Татарстан Республикасының Экология һәм табигый байлыклар министрлыгы |
| Төбәк программасының төп эшләүчесе | Татарстан Республикасының Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы |
| Төбәк программасының максаты | Идел елгасына агызып төшерелә торган пычрак суларның өлешен өч тапкырга киметү |

<table>
<tr><td>Төбәк программасының бурычлары</td><td>Сууткәргеч-канализация хуҗалыгы предприятиеләренең агызыла торган пычрак сулары өлешен киметү</td></tr>
<tr><td>Төбәк программасын тормышка ашыру вакытлары</td><td>2019 – 2024 еллар</td></tr>
<tr><td>Үзәкләштерелгән су чыгару системаларының чистарту корылмаларын төзү һәм реконструкцияләү (модернизацияләү) объектлары саны</td><td>24 объект</td></tr>
<tr><td>Елларга һәм чыганакларга бүлеп, Төбәк программасын финанслау күләме</td><td>2019 – 2024 елларда Төбәк программасын финанслауның гомуми күләме 11 814 448,9 мең сум тәшкил итәчәк, шул исәптән:<br>(мең сум)
<table>
<tr><td rowspan="2">Ел</td><td rowspan="2">Барлыгы</td><td colspan="3">Шул исәптән</td></tr>
<tr><td>Татарстан Республикасы бюджеты акчасы</td><td>җәлеп итәргә планлаштырыла торган федераль бюджет акчасы</td><td>бюджеттан тыш акча</td></tr>
<tr><td>2019</td><td>2 450 867,6</td><td>352 799,5</td><td>1 504 040,0</td><td>594 028,1</td></tr>
<tr><td>2020</td><td>2 092 924,0</td><td>360 962,0</td><td>1 538 838,0</td><td>193 124,0</td></tr>
<tr><td>2021</td><td>1 699 263,3</td><td>285 459,3</td><td>1 216 958,0</td><td>196 846,0</td></tr>
<tr><td>2022</td><td>1 463 824,0</td><td>239 210,0</td><td>1 019 770,0</td><td>204 844,0</td></tr>
<tr><td>2023</td><td>1 770 960,0</td><td>297 250,0</td><td>1 267 220,0</td><td>206 490,0</td></tr>
<tr><td>2024</td><td>2 336 610,0</td><td>406 080,0</td><td>1 731 190,0</td><td>199 340,0</td></tr>
<tr><td>Барлыгы</td><td>11 814 448,9</td><td>1 941 760,8</td><td>8 278 016,0</td><td>1 594 672,1</td></tr>
</table>
Искәрмә: финанслау күләмнәре фараз характерында була һәм аларга, тиешле бюджетлар мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш</td></tr>
<tr><td>Төбәк программасы максатларын һәм бурычларын тормышка ашырудан көтелә торган соңгы нәтиҗәләр (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары) һәм бюджет нәтиҗәлелеге күрсәткечләре</td><td>Төбәк программасы чараларын тормышка ашыру түбәндәгеләргә мөмкинлек бирәчәк:<br>2024 ел йомгаклары буенча Идел елгасына агызып төшерелә торган пычрак суларның күләмен 1 елга 0,06 куб. километрга кадәр киметергә, шул исәптән:<br>2019 ел – 1 елга 0,19 куб. километрга кадәр;<br>2020 ел – 1 елга 0,18 куб. километрга кадәр;<br>2021 ел – 1 елга 0,16 куб. километрга кадәр;<br>2022 ел – 1 елга 0,13 куб. километрга кадәр;<br>2023 ел – 1 елга 0,1 куб. километрга кадәр;<br>2024 ел – 1 елга 0,06 куб. километрга кадәр;<br>2024 ел йомгаклары буенча Идел елгасына агызып төшерелә торган пычрак суларны агызуны киметүне</td></tr>
</table>

| | |
|---|---|
| | тәэмин итә торган чистарту корылмалары егәрлеге 1 елга 0,13 куб. километрга кадәр артуны тәэмин итәргә, шул исәптән:<br>2019 ел – 1 елга 0,0 куб. километрга кадәр;<br>2020 ел – 1 елга 0,01 куб. километрга кадәр;<br>2021 ел – 1 елга 0,03 куб. километрга кадәр;<br>2022 ел – 1 елга 0,05 куб. километрга кадәр;<br>2023 ел – 1 елга 0,09 куб. километрга кадәр;<br>2024 ел – 1 елга 0,13 куб. километрга кадәр.<br>Бюджет нәтиҗәлелеге күрсәткечләрен исәпләү бу Төбәк программасының VIII бүлегендә китерелде |

## III. Төбәк программасын үтәүдә катнашучы Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре исемлеге

Төбәк программасын үтәүдә катнашучы Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре исемлеге әлеге муниципаль берәмлекләр территориясендә Идел елгасы бассейнына карый торган су агымы үтүен исәпкә алып төзелде.

Төбәк программасын тормышка ашыруда түбәндәге муниципаль берәмлекләр катнаша: Әгерҗе муниципаль районы, Алексеевск муниципаль районы, Бөгелмә муниципаль районы, Буа муниципаль районы, Биектау муниципаль районы, Алабуга муниципаль районы, Зәй муниципаль районы, Зеленодольск муниципаль районы, Лаеш муниципаль районы, Минзәлә муниципаль районы, Питрәч муниципаль районы, Тәтеш муниципаль районы, Казан шәһәре, Яр Чаллы шәһәре.

## IV. Төбәк программасын тормышка ашыру өлкәсе характеристикасы, экологик хәлне яхшырту чаралары тасвирламасы

Төбәк программасы Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының 2019 елның 30 апрелендәге 254/пр номерлы боерыгы белән расланган Үзәкләштерелгән су чыгару системаларының чистарту корылмаларын төзү һәм реконструкцияләү (модернизацияләү) буенча төбәк программаларын әзерләү буенча методик тәкъдимнамәләр таләпләрен исәпкә алып эшләнде.

Су объектларының торышы дәүләтнең социаль, икътисадый һәм экологик иминлеген билгели торган өлешләрнең берсе булып тора.

Татарстан Республикасында коммуналь хуҗалык канализациясенең 86 чистарту корылмасы, 348 канализация насос станциясе эксплуатацияләнә.

Республикада эшли торган канализация чистарту корылмаларының билгеләнгән үткәрү сәләте тәүлегенә 1,73 млн.куб.метр тәшкил итә. Канализациянең чистарту корылмалары аша суларны үткәрү тәүлегенә 709,9 мең куб.метр тәшкил итә.

Агызыла торган суларны тулысынча биологик чистарта торган чистарту корылмалары Казан, Яр Чаллы, Әлмәт, Бөгелмә, Алабуга, Зеленодольск, Лениногорск, Чистай, Зәй, Тәтеш, Нурлат, Менделеевск шәһәрләрендә, Урыссу

шәһәр тибындагы поселогында файдаланыла.

Канализация челтәрләренең озынлыгы якынча 4,5 мең км тәшкил итә, шуларның 1,7 мең километры алмаштыруны таләп итә.

Татарстан Республикасында канализациянең гамәлдәге чистарту корылмалары торышын мониторинглау күрсәтүенчә, кайбер шәһәрләрдә һәм район үзәкләрендә үзәкләштерелгән су чыгару системалары объектларының тузу проценты югары, алар канәгатьләндерерлек итеп эшлими һәм, халык сәламәтлегенә куркыныч тудырып, су объектларына нормативларга туры килми торган агызыла торган суларны чыгаруны дәвам итәләр.

Чистарту корылмаларының күпчелеге реконструкцияләүне, агызыла торган суларны чистартып бетерү җайланмаларын урнаштыруны таләп итә. Тиешле дәрәҗәдә чистартылмаган агызыла торган суларны агызу сәбәпләренең берсе – агызыла торган суларны чистартуның искергән технологияләрен куллану, канализация хуҗалыгының төп фондлары физик яктан шактый тузган булу. Агызыла торган суларны чистартуның таләп ителә торган параметрларына ирешү өчен канализациянең чистарту корылмаларын модернизацияләргә һәм реконструкцияләргә кирәк.

Күп кенә авыл торак пунктларында үзәкләштерелгән су чыгару системасы юк.

Агызып төшерелә торган суларның сыйфатын норматив күрсәткечләргә җиткерү юлы белән экологик хәлне яхшырту максатларында, республикада 2017 – 2018 елларда Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән 61 су чыгару объекты төзелде (реконструкцияләнде) һәм капиталь ремонтланды, гомуми суммасы 317,6 млн.сум тәшкил итте.

Мәсьәләне суүткәргеч-канализация хуҗалыгы предприятиеләренең үз акчасы хисабына хәл итү мөмкин түгел, чөнки кирәкле чараларның суммасы зур бәя тора.

## V. Төбәк программасының төп максаты һәм бурычлары, көтелә торган соңгы нәтиҗәләрне тасвирлау, аны тормышка ашыру вакытлары һәм этаплары

Төбәк программасының максаты – Идел елгасына агызып төшерелә торган пычрак суларның өлешен өч тапкырга киметү.

Төп максатка ирешү өчен түбәндәге өстенлекле бурычларны комплекслы, системалы һәм максатчан хәл итәргә кирәк:

су чыгару һәм агызыла торган суларны чистарту секторында сектор эшчәнлегенең нәтиҗәлелегенә һәм ышанычлылыгына юнәлдерелгән коммуналь инфраструктура системаларын үстерү;

су чыгару һәм агызыла торган суларны чистарту секторына озак вакытка исәпләнгән шәхси инвестицияләр җәлеп итү өчен шартлар тудыру;

хуҗалыкны һәм эчәргә яраклы су белән тәэмин итү чыганаклары булган сулыкларга норматив кебек булмаган чистартылган агызыла торган суларны агызу күләмнәрен киметү.

2019 – 2024 елларда Төбәк программасының максатына ирешү һәм бурычларын үтәү өчен үзәкләштерелгән су чыгару системаларының чистарту

корылмаларын төзү һәм реконструкцияләү (модернизацияләү) буенча чаралар тормышка ашырылачак.

Төбәк программасы чараларын тормышка ашыру түбәндәгеләргә мөмкинлек бирәчәк:

2024 ел йомгаклары буенча Идел елгасына агызып төшерелә торган пычрак суларның күләмен 1 елга 0,06 куб. километрга кадәр киметергә, шул исәптән:

2019 ел – 1 елга 0,19 куб. километрга кадәр;
2020 ел – 1 елга 0,18 куб. километрга кадәр;
2021 ел – 1 елга 0,16 куб. километрга кадәр;
2022 ел – 1 елга 0,13 куб. километрга кадәр;
2023 ел – 1 елга 0,1 куб. километрга кадәр;
2024 ел – 1 елга 0,06 куб. километрга кадәр;

2024 ел йомгаклары буенча Идел елгасына агызып төшерелә торган пычрак суларны агызуны киметүне тәэмин итә торган чистарту корылмалары егәрлеге 1 елга 0,13 куб. километрга кадәр артуны тәэмин итәргә, шул исәптән:

2019 ел – 1 елга 0,0 куб. километрга кадәр;
2020 ел – 1 елга 0,01 куб. километрга кадәр;
2021 ел – 1 елга 0,03 куб. километрга кадәр;
2022 ел – 1 елга 0,05 куб. километрга кадәр;
2023 ел – 1 елга 0,09 куб. километрга кадәр;
2024 ел – 1 елга 0,13 куб. километрга кадәр.

## VI. Төбәк программасының ресурслар белән тәэмин ителеше

Төбәк программасын финанслауның гомуми күләме 11 814 448,9 мең сум тәшкил итә, шул исәптән:

(мең сум)

| Ел | Барлыгы | Шул исәптән | | |
|---|---|---|---|---|
| | | Татарстан Республикасы бюджеты акчасы | җәлеп итәргә планлаштырыла торган федераль бюджет акчасы | бюджеттан тыш акча |
| 2019 | 2 450 867,6 | 352 799,5 | 1 504 040,0 | 594 028,1 |
| 2020 | 2 092 924,0 | 360 962,0 | 1 538 838,0 | 193 124,0 |
| 2021 | 1 699 263,3 | 285 459,3 | 1 216 958,0 | 196 846,0 |
| 2022 | 1 463 824,0 | 239 210,0 | 1 019 770,0 | 204 844,0 |
| 2023 | 1 770 960,0 | 297 250,0 | 1 267 220,0 | 206 490,0 |
| 2024 | 2 336 610,0 | 406 080,0 | 1 731 190,0 | 199 340,0 |
| Барлыгы | 11 814 448,9 | 1 941 760,8 | 8 278 016,0 | 1 594 672,1 |

Искәрмә: финанслау күләмнәре фараз характерында була һәм аларга, тиешле бюджетлар мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш.

## VII. Төбәк программасын тормышка ашыру механизмы

Татарстан Республикасының Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы планлаштыруны, үзара хезмәттәшлек итүне,

координацияләүне һәм Төбәк программасы үтәлешен гомуми тикшерүдә тотуны гамәлгә ашыра.

Татарстан Республикасының Экология һәм табигый байлыклар министрлыгы Төбәк программасы чаралары исемлеген килештерүне тәэмин итә, Төбәк программасын тормышка ашыруда катнашучыларга методологик ярдәм күрсәтә.

«Татарстан Республикасының Баш инвестиция-төзелеш идарәсе» дәүләт казна учреждениесе бюджет акчасын алучы һәм Төбәк программасы чараларын үтәүче булып тора, ул сатып алуларны, аукционнар оештыруны һәм үткәрүне, дәүләт контрактларын төзүне гамәлгә ашыра, заказчы-төзүче функцияләрен башкара, проект документларына экспертиза үткәрүне тәэмин итә, төзелеш контролен гамәлгә ашыра.

Төбәк программасын тормышка ашырганда социаль һәм экологик куркынычлар юк.

## VIII. Федераль бюджеттан инвестицияләрнең бюджет нәтиҗәлелеген исәпләү

| Рейтингтагы позициясе | Объектның исеме | Федераль бюджеттан инвестицияләр күләме, мең сум | Объекттан агызып чыгарыла торган пычрак сулар күләмен киметүнең план буенча күрсәткече, 1 тәүлеккә мең.куб.метр | Бюджет нәтиҗәлелеге күрсәткеченең мәгънәсе, сум/куб.метр |
|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| 1. | Казан шәһәрендәге канализациянең биологик чистарту корылмаларын реконструкцияләү, 1 нче этап | 3 141 488,4 | 650,0 | 4 833,059 |
| 2. | Казан шәһәрендәге канализациянең биологик чистарту корылмаларын реконструкцияләү, 2 нче этап | | | |
| 3. | Казан шәһәрендәге Канализациянең биологик чистарту корылмаларын реконструкцияләү, 3 нче этап | | | |
| 4. | Бөгелмә шәһәрендәге канализациянең чистарту корылмаларын реконструкцияләү | 121 500,0 | 22,0 | 5 522,727 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| 5. | Казан шәһәрендә утырымны механик сусызландыру цехы белән тәүлегенә 80 мең куб.м. җитештерүчәнлекле юдыру суларын чистарту корылмалары төзү | 916 154,8 | 80,0 | 11 451,935 |
| 6. | «Салават Күпере» торак районы өчен инженерлык-техник тәэмин итү челтәрләре төзү. Хуҗалык-көнкүреш канализациясе челтәрләре. 6 нчы этап: Васильево шәһәр тибындагы поселогының тәүлегенә 24 тыс.м3 җитештерүчәнлекле биологик чистарту корылмалары, шул исәптән: беренче чират – тәүлегенә 12 тыс.м3 кадәр | 143 318,354 | 12,0 | 11 943,196 |
| 7. | Яр Чаллы шәһәренең яңгыр сулары канализациясен төзү 1 нче этап | 343 883,924 | 22,598 | 15 217,449 |
| 8. | «Салават Күпере» торак районы өчен инженерлык-техник тәэмин итү челтәрләрен төзү. Хуҗалык-көнкүреш канализациясе челтәрләре. 6 нчы этап: Васильево шәһәр тибындагы поселогының тәүлегенә 32 тыс.м3 кадәр җитештерүчәнлекле биологик чистарту корылмалары, икенче чират | 508 624,782 | 24,0 | 21 192,699 |
| 9. | Казан шәһәренең Ветеринария академиясе районындагы су объектларына яңгыр канализациясе чыгару урыннарында өске агызыла торган суларны чистарту корылмалары | 74 044,822 | 2,592 | 28 566,675 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| | төзү | | | |
| 10. | Тәтеш шәһәрендә яңгыр сулары канализациясен урнаштыру | 88 155,629 | 3,024 | 29 151,994 |
| 11. | Буа шәһәрендәге канализациянең биологик чистарту корылмаларын реконструкцияләү | 149 040,0 | 4,28 | 34 822,43 |
| 12. | Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Питрәч авылында биологик чистарту корылмалары төзү | 121 500,0 | 3,0 | 40 500,0 |
| 13. | Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Кощаково авылында биологик чистарту корылмалары төзү | 72 900,0 | 1,5 | 48 600,0 |
| 14. | Минзәлә шәһәрендә, егәрлеген арттырып, гамәлдәге чистарту корылмаларын реконструкцияләү | 307 800,0 | 5,4 | 57 000,0 |
| 15. | «Алабуга» сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зонасы һәм Алабуга шәһәре»нең көнкүреш һәм сәнәгать агызыла торган суларын район чистарту корылмаларын реконструкцияләү I һәм II этаплар | 1 158 172,597 | 19,5 | 59 393,467 |
| 16. | «Алабуга» сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зонасы һәм Алабуга шәһәре»нең көнкүреш һәм сәнәгать агызыла торган суларын район чистарту корылмаларын реконструкцияләү I һәм II этаплар | | | |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| 17. | Лаеш шәһәренең су чыгару системасын реконструкцияләү | 69 417,0 | 0,7 | 99 167,143 |
| 18. | Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Алексеевск шәһәр тибындагы поселогында чистарту корылмалары төзү | 120 142,156 | 1,2 | 100 118,463 |
| 19. | Казан шәһәренең Авиатөзелеш районындагы Крутушка торак пункты канализациясенең чистарту корылмаларын реконструкцияләү | 82 620,0 | 0,8 | 103 275,0 |
| 20. | Чистарту корылмалары төзү, Зәй шәһәре, Поповка авыл җирлеге, Зәй муниципаль районы, Татарстан Республикасы | 71 168,212 | 0,6 | 118 613,687 |
| 21. | Биектау авылының биологик чистарту корылмаларын һәм тышкы су чыгару челтәрләрен төзү | 243 000,0 | 2,0 | 121 500,0 |
| 22. | Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының Карамалы Тау шәһәре тибындагы поселогында канализациянең биологик чистарту корылмаларын реконструкцияләү | 157 950,0 | 1,05 | 150 428,571 |
| 23. | Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Кызыл Бор авылында биологик чистарту корылмалары төзү | 43 366,136 | 0,15 | 289 107,573 |
| 24. | Минзәлә муниципаль районының Юртау поселогында биологик чистарту корылмалары төзү | 24 300,0 | 0,075 | 324 000,0 |
| | Барлыгы | 7 958 546,8 | 856,469 | 9 292,277 |
| | Бүленмәгән лимит | 319 469,188 | | |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| | Барысы бергә | 8 278 016,0 | | |

Чараларны тормышка ашыру чираты проект-смета документларының булуын, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының проект-смета документларын эшләүгә акча бүлеп бирү турындагы боерыгының булуын һәм һәр елга аны тормышка ашыру өчен төбәк программасының максатчан күрсәткечен үтәү кирәклеген исәпкә алып билгеләнде.

## IX. Ресурслар белән тәэмин итүче оешмаларның инвестиция программаларында каралган финанс чаралары күләме

2019 – 2024 елларда Казан шәһәренең «Водоканал» муниципаль унитар предприятиесенең үзәкләштерелгән су чыгару системалары объектларын төзү, модернизацияләү һәм (яки) реконструкцияләүгә каралган финанс чаралары күләме бюджеттан тыш акча исәбеннән 1 214 425,0 мең сум тәшкил итәчәк, шул исәптән:

2019 елда – 213 781,0 мең сум;
2020 елда – 193 124,0 мең сум;
2021 елда – 196 846,0 мең сум;
2022 елда – 204 844,0 мең сум;
2023 елда – 206 490,0 мең сум;
2024 елда – 199 340,0 мең сум.

2019 – 2024 елларга Татарстан Республикасында үзәкләштерелгән су чыгару системаларының чистарту корылмаларын төзү һәм реконструкцияләү (модернизацияләү) буенча төбәк программасы объектлары характеристикасы бу Төбәк программасына теркәлгән 1 нче кушымтада бирелә.

2019 – 2024 елларга Татарстан Республикасында үзәкләштерелгән су чыгару системаларының чистарту корылмаларын төзү һәм реконструкцияләү (модернизацияләү) буенча төбәк программасын тормышка ашыруның финанслар белән тәэмин итү бу Төбәк программасына теркәлгән 2 нче кушымтада бирелә.

2019 – 2024 елларга Татарстан Республикасында үзәкләштерелгән су чыгару системаларының чистарту корылмаларын төзү һәм реконструкцияләү (модернизацияләү) буенча төбәк программасын тормышка ашырганда «Иделне савыктыру» федераль проектының «Идел елгасына агызып төшерелә торган пычрак суларның күләмен киметү» максатчан күрсәткеченә ирешү динамикасы бу Төбәк программасына теркәлгән 3 нче кушымтада бирелә.

2019 – 2024 елларга Татарстан Республикасында үзәкләштерелгән су чыгару системаларының чистарту корылмаларын төзү һәм реконструкцияләү (модернизацияләү) буенча төбәк программасын тормышка ашыру этаплары бу Төбәк программасына теркәлгән 4 нче кушымтада бирелә.

2019 – 2024 елларга Татарстан Республикасында үзәкләштерелгән су чыгару системаларының чистарту корылмаларын төзү һәм реконструкцияләү (модернизацияләү) буенча төбәк программасы чараларын тормышка ашыруның тариф нәтиҗәләре фаразы бу Төбәк программасына теркәлгән 5 нче кушымтада бирелә.